КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 48

2024 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында

2024 елгы язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехника корылмаларын, юлларны һәм күперләрне саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары планын (алга таба – План) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына, шулай ук гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, Татарстан Республикасының барлык дәрәҗәләрдәге янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләренә, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм Планда күрсәтелгән оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

План чаралары үтәлешен тәэмин итүне;

гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләре белән җитәкчелек итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары нигезендә гамәлгә ашыруны;

2024 елның 1 апреленә кадәр – Планны тормышка ашыру турындагы һәм 2024 елның 15 маена кадәр язгы ташу узу нәтиҗәләре хакындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына кертүне.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына 2024 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә язгы ташу нәтиҗәләре турында мәгълүмати-аналитик хисап тапшырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 гыйнвар,  48 нче
карары белән расланды

## 2024 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Оештыру чаралары | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен 2024 елгы язгы ташуга әзерләү чаралары үтәлешен тикшерү графигын төзү | Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе эшче төркеме (алга таба – Татарстан Республикасы ГХКБ һәм ЯКТ комиссиясе), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (алга таба - Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе) (килешү буенча) | 05.03.2024 кадәр |
| 2. | Язгы ташу китерә торган зыяннарны киметү һәм бетерү өчен кичектергесез чаралар күрүне таләп итә торган мәсьәләләрне даими рәвештә карап тикшерү | Татарстан Республикасы ГХКБ һәм ЯКТ, Татарстан Республикасы ГТХМ эшче төркеме | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 3. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләренә (алга таба – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең ГХКБ һәм ЯКТ) язгы ташуга каршы һәм кисәтү | Татарстан Республикасы ГХКБ һәм ЯКТ комиссиясе, Татарстан Республикасы ГТХМ эшче төркеме, Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | чараларын әзерләүдә һәм үткәрүдә оештыру-методик ярдәм күрсәтү (килешү буенча) | | |
| 4. | Язгы ташуга каршы чараларны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү максатларында, республиканың су басарга мөмкин булган зонага туры килә торган торак пунктларына Татарстан Республикасы ГТХМ хезмәткәрләренең баруын оештыру | Татарстан Республикасы ГТХМ, Татарстан Республикасы ГХКБ һәм ЯКТ комиссиясе | 20.03.2024 кадәр |
| 5. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына көтелә торган су ташу характе-ристикасы, Татарстан Республикасы елгаларында суның максималь баскычлары фаразы, елгаларны ачу һәм сусаклагычларны чистарту сроклары фаразлары бирү | «Татарстан Республикасы гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) | 15.03.2024 кадәр |
| 6. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсендә су объектларының агымдагы торышы турында белешмәләр (көн саен уздырылучы мәгълүмати гидрометеорологик бюллетень кысаларында) бирү | «Татарстан Республикасы ГӘТММИ» ФДБУ (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 7. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына Идел-Кама каскады сусаклагычындагы су агымының фаразларын бирү | «Татарстан Республикасы ГӘТММИ» ФДБУ (килешү буенча) | 15.03.2024 – 01.06.2024 |
| 8. | Республика территориясен су басарга мөмкин булган зоналар буенча районнарга бүлү һәм көтелә торган метеошартлар турындагы мәгълүматлар нигезендә язгы ташу китереп чыгарырга мөмкин булган һәм иң начар сценариеләрен үзгәрү модельләрен һәм фараз-исәп-хисап сценарийларын әзерләү | Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 9. | Республиканың су объектларында суның дәрәҗәсен, куркыныч хәлләр килеп чыгарга мөмкин булган һәм | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә | ташу башланганчы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | авария хәлендәге гидротехника корылмаларының торышын тикшерүдә тоту өчен вакытлыча күзәтү челтәре (гидрология постлары) эшчәнлеген оештыру | органнары) (килешү буенча), муниципаль берәмлекләрнең ГТХКһәмЯКТИК (килешү буенча) | |
| 10. | Язгы ташу торышы үсешенә бәйле прогностик һәм мониторинг мәгълүматларын тапшыруның вакытында һәм тулылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 11. | 2024 елгы язгы ташуга әзерлек мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлекләрнең ГТХКһәмЯКТИК комиссияләре утырышларын үткәрү. Үткән елларда язгы ташу узу нәтиҗәләрен исәпкә алып, язгы ташуга каршы үткәрелгән чараларны бәяләү | Муниципаль берәмлекләрнең ГТХКһәмЯКТИК (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | 20.03.2024 кадәр |
| 12. | Язгы ташу сулары басарга мөмкин булган зоналардан халыкны, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм матди байлыкларны өлешчә эвакуацияләү (күчерү) планнарын тәгаенләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 20.03.2024 кадәр |
| 13. | Язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне саклау буенча муниципаль берәмлекләрнең ГТХКһәмЯКТИК комиссияләре, оператив төркемнәр гамәлләре күнегүләрен үткәрү | муниципаль берәмлекләрнең ГТХКһәмЯКТИК комиссияләре рәисләре (килешү буенча) | 20.03.2024 кадәр |
| 14. | Халыкка, муниципаль берәмлекләрнең ГХКБ һәм ЯКТ комиссияләренә хәбәр итү системаларының эшләргә яраклы булу-булмавын тикшерү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 15.03.2024 кадәр |
| 15. | Су басу зонасына туры килә торган торак пунктлар белән радиоэлемтә оештыру, элемтә көчләрен һәм чараларын исәпләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 15.03.2024 кадәр |
| 16. | Сыек калдыклар туплану, агулы химикатлар саклау урыннарында һәм чистарту корылмаларында өске суларның сыйфатын тикшерүдә тотуны оештыру | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (вәкаләтләр кысаларында), Ветеринария һәм фитосанитар күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | язгы ташу чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 17. | Муниципаль берәмлекләрнең ГХКБ һәм ЯКТ эшче (оператив) төркемнәрен формалаштыру һәм аларның әзерлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | 15.03.2024 кадәр |
| 18. | Татарстан Республикасының су объектларында боз тыгылган урыннарны бетерү буенча шартлату эшләрен үткәрү өчен шартлаткыч матдәләрне һәм шартлату чараларын транспортта ташыганда аларны озата баруны тәэмин итү | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 19. | Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсендә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына 2024 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм территорияне яклау чараларына җәлеп ителә торган чаралар һәм чаралар буенча белешмәләр бирү | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасы дәүләт медицина иминияте» ФДБУ (килешү буенча) һәм җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.02.2024 кадәр |
| 20. | Язгы ташу аркасында гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда кешеләргә үз-үзләрен тоту кагыйдәләре турында мәгълүмат җиткерү | Татарстан Республикасы ГТХМ һәм Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 21. | 2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә язгы ташу чорында хәвеф-хәтәрләрне йомшарту һәм гадәттән тыш хәлләргә реакция ясау планына төзәтмәләр кертү | Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 15.02.2024 кадәр |
| 22. | 2024 елгы язгы ташу узган чорда Татарстан Республикасы халкын һәм территорияләрен саклау чараларына җәлеп ителә торган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары һәм оешмалар | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.03.2024 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | арасында үзара мәгълүмати хезмәттәшлек оештыру турындагы килешүләргә төзәтмәләр кертү | | |
| 23. | Гидротехника корылмаларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә мәгълүмат җыюны һәм эшкәртүне гамәлгә ашыру, шулай ук әлеге мәгълүматны мәнфәгатьле министрлыклар һәм ведомстволар белән уртаклашу | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 24. | Муниципаль берәмлекләрнең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләре тарафыннан гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасына караган тиешле муниципаль звенолар составына керә торган ведомстволарның, оешмаларның кизү-диспетчерлык хезмәтләре белән күнегүләр үткәрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | аерым план буенча |
| 25. | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының идарә органнары һәм көчләре белән язгы ташу куркынычы чорында региональ һәм муниципаль дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча комплекслы өйрәнүләрне оештыру һәм уздыру | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 31.03.2024 кә кадәр |
| 26. | Язгы ташу, табигый янгыннар белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, урман янгыннарыннан икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын яклау мәсьәләләрен хәл итү, шулай ук урман янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләр һәм чаралар белән төбәкара маневрлау мәсьәләләрен җайга салу буенча уртак комплекслы өйрәнүләрдә катнашу | Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГХКБ һәм ЯКТ комиссиясе, Татарстан Республикасы ГТХМ, дәүләт хакимиятенең территориаль органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары һәм оешмалары (килешү буенча) | 2024 елның II кварталы |
| 27. | Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Түбән Новгород өлкәсе буенча Баш идарәсе | Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | 2024 елның I кварталы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | җитәкчелегендә язгы ташуны авариясез үткәрү мәсьәләләрен хәл итү буенча штаб күнегүләре үткәрү | | |
| Гамәли чаралар | | | |
| 1. | Боз тыгылган урыннарны бетерү буенча кече елгалар участок-ларында шартлату эшләрен үткәрүне оештыру | Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | язгы ташу чорында |
| 2. | Гидротехника корылмаларын (инженерлык саклагыч объектларын, буаларны, плотиналарны, дамбаларны һ.б.) кар суларының мөмкин булган иң зур күләмнәрен уздырып җибәрүгә әзерләү эшләрен үткәрүне оештыру, шулай ук сусаклагычларның (буаларның) кышкы (куркынычсыз) күләменә кадәр саклап калу һәм су чыгаруда задвижкаларны җайга салу юлы белән гидротехник корылмаларның эш режимын саклау | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 10.03.2024 кадәр |
| 3. | Боз тупланмалары барлыкка килүне һәм боз кисәкләре бер урынга җыелуны кисәтү, бозларны ваклауны оештыру, гидротехника корылмаларының барлык фронты буенча суагызгыч тишемнәрдән боз өемнәрен үткәреп җибәрү | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 4. | Интенсив язгы ташулар фаразланган очракта, инженерлык саклагыч корылмаларга күзәтчелек итүне көчәйтү, тәүлек буе кизү тору һәм ышанычлы элемтә һәм хәбәр итү системасын оештыру | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 5. | Татарстан Республикасы су объектларының су басу куркынычы булган участокларында бозны вату һәм кисү эшләрен башкаруны оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2024 елның марты |
| 6. | Су басарга мөмкин булган торак пунктлар янында халыкка авиация техникасын кулланып ярдәм күрсәтү өчен вакытлыча вертолет мәйданчыкларын (мөмкинлек булганда) әзерләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.03.2024 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7. | Муниципаль берәмлекләрнең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләрен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасына караган муниципаль звено составына керүче оешмаларның, ведомстволарның кизү-диспетчерлык хезмәтләре, җаваплы вазыйфаи затлары турында мәгълүматлар белән актуальләштерелгән телефон белешмәлекләре белән тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.03.2024 кадәр |
| 8. | Кышкы чорның тискәре зыяннарын һәм ремонт вакытында эшләп бетерелмәгән эшләрне үз вакытында ачыклау һәм җиренә җиткереп эшләп бетерү максатларыннан чыгып, мелиорация системаларын һәм гидротехник корылмаларны кабат тикшерү | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 25.03.2024 кадәр |
| 9. | Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә халыкка һәм территориягә куркыныч тудыручы, имин эксплуатацияләүне тәэмин итеп булмый торган гидротехника корылмалары булу-булмауга тикшерүләр үткәрү | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 20.03.2024 кадәр |
| 10. | Язгы ташу алды һәм язгы ташу чорларында сусаклагычларның оптималь дәрәҗәләренә ирешү өчен Куйбышев һәмТүбән Кама сусаклагычларының эш режимнарын билгеләү буенча Су ресурслары федераль агентлыгының Идел-Кама каскады сусаклагычлары эш режимнарын җайга салу буенча ведомствоара оператив төркемгә тәкъдимнәр әзерләү | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы ГТХМ | 01.06.2024 кадәр |
| 11. | Якын тирәдәге территорияләрнең су астында калуына юл куймау буенча үз вакытында чаралар күрү һәм су басу куркынычы булган очракта халыкка хәбәр итү өчен сусаклагычларның билгеләнгән эш режимын саклауны тикшерүдә тоту | Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны сулары идарәсенә караган Татарстан Республикасы буенча Су ресурслары бүлеге (килешү буенча), «Үзәк төбәк су хуҗалыгы» федераль дәүләт бюджет су хуҗалыгы учреждениесенең «Средволга-водхоз» филиалы (алга таба - «Средволгаводхоз» | язгы ташу чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | филиалы) (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | |
| 12. | Россия Федерациясе субъекты милкендә, муниципаль милектә булган гидротехника корылмаларына һәм хуҗасыз гидротехника корылмаларына капиталь ремонт үткәрүне гамәлгә ашыру, шулай ук «Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» федераль максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында хуҗасыз гидротехника корылмаларын бетерү өчен федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субсидияләр исәбеннән 2024 елда капиталь ремонт үткәрелергә тиешле гидротехника корылмалары исемлеген билгеләү | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары | 01.05.2024 кадәр |
| 13. | Авария яки авария алды хәлендәге, шулай ук милеккә хокуклары теркәлмәгән (кабул итү-тапшыру актлары буенча тапшырылган) гидротехника корылмаларына комиссион тикшерү үткәрү. Гидротехника корылмаларын тикшерү актларын төзү Гидротехник корылмаларны тикшерү актларын төзү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | 30.04.2024 кадәр |
| 14. | Су объектларының су саклау зоналарын пычратуга һәм язгы ташу суларының сыйфатын начарайтуга юл куймау буенча (бигрәк тә сыек калдыклар туплана торган районнарда, чистарту корылмалары һәм агулы химикатлар саклау, елгаларның һәм сулыкларның боз өстенә автотранспорт керү, ведомстволар причаллары һәм елга транспортының төяү-бушату урыннарында) оештыру чараларын һәм инженер-техник чаралар үткәрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (вәкаләтләр кысаларында), “Средволгаводхоз” филиалы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 2024 елның 15 мартына кадәр – оештыру чаралары, су ташу чорында гамәли чаралар |
| 15. | Язгы ташу сулары басарга мөмкин булган зонага туры килә торган авыл хуҗалыгы объектларын һәм терлекләр күмелгән урыннарны (шул исәптән түләмә авырулы терлекләр күмелгән урыннарны) тикшерү. Үләт базларын су басуны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештыру | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.04.2024 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 16. | Шәһәрләрдәге һәм районнардагы юлларда кар суларының иң зур күләмнәрен агызып җибәрү өчен су үткәрү торбаларын, канауларны, каналларны, җыелган яңгыр сулары канализациясе корылмаларын чистарту чараларын үткәрүне оештыру | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – «Главтатдортранс» ДКУ), «Федераль юллар агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесе (алга таба – «Идел-Нократ управтодор» ФКУ) (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 17. | Су басарга мөмкин булган зонага туры килә торган электр белән тәэмин итүче кабель линияләренә, трансформаторлы ярдәмче станцияләргә тикшерү үткәрү. Аларны имин эксплуатацияләү чараларын күрү | «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе (килешү буенча), «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) | 2024 елның 25 мартына кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 18. | Күперләрне тикшерү һәм ныгыту, аларны торгызу өчен материаллар һәм чаралар әзерләү. Куркыныч ихтималы булган суга якын урнашкан ясалма корылмаларны аеруча тикшерүдә тоту. Вакытлыча кичүләр һәм аркылы чыгу урыннарын урыннарын билгеләү | «Главтатдортранс» ДКУ, «Идел-Урал управтодор» ФКУ (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 19. | Автоюлларның һәм ясалма корылмаларның язгы ташу узу чорында эшләргә әзерлеген һәм аларны карап тоту дәрәҗәсен билгеләү буенча тикшерүләр оештыру | «Главтатдортранс» ДКУ, «Идел-Урал управтодор» ФКУ (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 20. | Су басарга мөмкин булган зоналарга туры килә торган торак биналардан һәм халыкның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү системалары объектларыннан кар суларын агызып җибәрү эшләрен оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2024 елның 25 мартына кадәр һәм язгы ташу чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 21. | Коммуналь хуҗалык объектларында язгы ташу китереп чыгарган гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының авария-техник запасыннан матди-техник чараларны оператив бирүне тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 2024 елның 25 мартына кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 22. | Йөзү чараларын, инженерлык, юл-төзелеш техникасын һәм башка кирәкле техниканы кичектергесез һәлакәт-торгызу эшләрен үткәрү очрагына әзерләү, аны кирәкле күләмдәге ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 20.03.2024 кадәр |
| 23. | Гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен түбәндәгеләр булдыру:<br>финанс, матди-техник чаралар;<br>инертлы һәм сорбентлаучы материаллар | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 20.03.2024 кадәр |
| 24. | Язгы ташу чорында зыян күргән кешеләргә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру буенча әзерлек эшләрен үткәрү. Медикаментларның кирәкле резервын яңартып тору | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.04.2024 кадәр |
| 25. | Язгы ташу чорында зыян күргән халыкның тереклек эшчәнлеген беренче чиратта тәэмин итүгә әзерлек эшләрен үткәрү | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.04.2024 кадәр |
| 26. | Суның сыйфаты начарайганда кичектергесез чаралар күрү өчен эчә торган сыйфатлы су әзерләү предприятиеләрендә зарарсызландыру чараларының, реагентларның өстәмә запасларын (иң кимендә бер ай эшләрлек) булдыруны тәэмин итү. Халыкка бирелә торган су белән тәэмин итү чыганакларының су сыйфатына һәм эчә торган суның сыйфатына җитештерү лаборатория контролен көчәйтергә | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектларының милекчеләре һәм баланс тотучылары (килештү буенча) | язгы ташу чорында |
| 27. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, «Идел буе федераль округы буенча җирләр | 15.05.2024 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 08 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне мелиорацияләүне үстерү» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гидротехник корылмаларны проектлау, төзү, реконструкцияләү, торгызу, плотиналарны һәм гидротехник корылмаларны капиталь ремонтлау эшләрен үз эченә алган мелиорация эшләре исемлеген раслау | мелиорациясе һәм авыл хуҗалыгы су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | |
| 28. | Торак пунктларны эчә торган су белән тәэмин итү чыганакларына су керү, аларны су басу очрагына эчә торган су китерү өчен шартлар тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 29. | 2024 елгы язгы ташу чорында махсус боз шартлату эшләрен үткәрү өчен «Татарстан Республикасы ГОЭ ГХМ каршындагы Татарстан Республикасының эзләү-коткару хезмәте» дәүләт казна учреждениесе базасында шартлатучылар командасын әзерләү | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 10.04.2024 кадәр |
| 30. | Халыкны үзәктән ераклаштырылган су белән тәэмин итү чыганакларына су керүне, су басуны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактика чаралары үткәрү. Су басу, су керү очракларында аларны юу һәм дезинфекцияләү буенча норматив документлар нигезендә чаралар күрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 31. | Йорт биләмәләре, шул исәптән санитар төеннәр, урам һәм каралтыдагы бәдрәфләре территорияләрен су баскан очракта, йортлар янындагы территорияләрдә дезинфекция чаралары үткәрү буенча чаралар күрергә. Дезинфекция чаралары үткәрүгә махсуслаштырылган оешмалар белән алдан килешүләр төзергә | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу беткәннән соң |
| 32. | Халыкны беренче чиратта тормыш белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле мөлкәт белән вакытлыча урнаштыру пунктлары әзерлеген тикшерүне оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 25.03.2024 кадәр |
| Контроль чаралары | | | |
| 1. | Торак-коммуналь, юл, энергетика, медицина предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренең язгы ташу чорына әзерлеге турындагы чыгышларын тыңлау | муниципаль берәмлекләрнең ГХКБ һәм ЯКТ комиссияләре (килешү буенча) | 25.03.2024 кадәр |
| 2. | 2024 елда ведомствоара комиссия тарафыннан муниципаль берәмлекләрнең су басу куркынычы янаган чорга әзерлеген гамәлгә ашыру | Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | 25.02.2024 – 05.03.2024 |
| 3. | Эчә торган суның сыйфатына, халыкны эчә торган су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган ачык су чыганакларының, су алу урыннарының торышына санитария-эпидемиология тикшерүен оештыру | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектлары хуҗалары һәм аларны баланста тотучылар (килешү буенча) | 10.05.2024 кадәр |
| 4. | Әлеге План чаралары үтәлешен муниципаль берәмлекләрнең ГХКБ һәм ЯКТ комиссияләре тарафыннан сайлап алып тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 01.04.2024 кадәр |
| 5. | Ведомство буйсынуындагы предприятиеләрнең һәм оешмаларның язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне саклау чараларын үткәрүгә әзерлеген һәм сыйфатын тикшерүдә тотуны оештыру | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы; | 01.04.2024 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6. | Халыкка су объектларының факттагы һәм көтелгән торышы, торак пунктларның һәм икътисад объектларының су басу ихтималы, халыкның куркынычсызлыгы янавы турында халыкка үз вакытында хәбәр итү | «Татарстан Республикасы ГӘТММИ» ФДБУ (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ һәм Россия ГХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | язгы ташу башланганга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 7. | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына һәм Россия ГХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә 2024 елда Татарстан Республикасы су объектларында язгы ташу үзенчәлекләре турында аналитик белешмә бирү | «Татарстан Республикасы ГӘТММИ» ФДБУ (килешү буенча) | язгы ташу чоры тәмамлангач |